Хатыйп Миңнегулов —
КФУ профессоры

# Чыңгыз Айтматов дулкынында

Очраклылыкмы, юкмы, — анысын белмим,— без фәкыйрегезгә соңгы ике айлап вакыт эчендә дистәләгән фәнни-гамәли конференциядә, гыйльми-мәдәни чараларда катнашырга, доклад-чыгышлар ясарга туры килде. Аларның күпчелеге күренекле шәхесләрнең түгәрәк даталары — юбилейлары белән бәйле иде: Таҗеддин Ялчыгол (тууына — 250 ел) [10 сентябрь, 2013 ел, Зәй шәһәре], Гаяз Исхакый (135 ел) [13 сентябрь, Чистай], Закир Кадыйри (135 ел) [14 сентябрь, Ульяновск], Әкъдәс Нигъмәт Курат (110 ел) [19 октябрь, Чирмешән районы Бәркәтә авылы], Чыңгыз Айтматов (тууына 85 ел) [27 октябрь, Кукмара; 6 ноябрь, Астана], Марат Әмирханов (тууына — 80 ел) [Язучыларның Тукай клубы] һ. б. Боларга «Шәрык-Гареб мөнәсәбәтләре кысаларында төрки халыкларның әдәбияты һәм мәдәнияте» (Казан, 17—18 октябрь), «Төрки әдәбиятлары тарихының чорларга бүленеше (Астана, 26—27 сентябрь) дип исемләнгән конференция-семинарлар да килеп өстәлде. Бу чаралар теге яки бу дәрәҗәдә радио-телевидениедә, көндәлек матбугат битләрендә чагылыш тапты. [Мәсәлән, Рәшит Минһаҗның безнең белән булган «Олы җаннар олы мирас калдырды» исемле интервьюсында Т. Ялчыгол, Г. Исхакый, З. Кадыйри белән бәйләнешле чаралар яктыртылды («Ватаным Татарстан». — 24. 09. 2013). Бәркәтәдәге кичә хакында мәгълүматлар «Мәдәни җомга»да (1. 10. 2013) бәян ителде. 10 ноябрь көнне «Татарстан» радиосы М. Әмирханов кичәсенең шактый тулы язмасын бирде]. Шунысы мөһим: бу төр конференция-кичәләр тар даирәдә генә түгел, киң җәмәгатьчелек катнашында уздырылды. Шуңа күрә алар иҗтимагый-мәдәни тормышта яңгыраш тапты һәм халкыбызны рухи яктан тәрбияләүгә билгеле бер өлеш тә кертте.

Соңгы вакытта үткәрелгән бу төр чаралар арасында, әлбәттә, төп урынны Чыңгыз Айтматовның 85 еллыгына багышланганнары алып торды. Ул бер генә көн түгел, ә атналар буе барды, халкыбыз һәм республика

тормышында истәлекле бер вакыйга, бәйрәм рәвешен алды. Тарихка «кыргыз әдибе» дип кереп калган язучының Татарстанда, татар дөньясында болай югары кимәлдә искә алынуы сирәк очрый торган күренеш. Моның, әлбәттә, үзенең билгеле бер сәбәпләре бар. Беренчедән, Ч. Айтматов — дөньякүләм мәшһүр, олуг әдип. Икенчедән, әнисе ягыннан аның нәсел-нәсәбе татарга, Кукмара төбәгенә барып тоташа.

## I

Чыңгыз Айтматов (12. 12. 1928 — 10. 06. 2008) — күпкырлы талант иясе: журналист, публицист, депутат, дипломат, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, югары белемле зоотехник... Әмма, барыннан да элек, ул — әдип. Бу затның күпкырлылыгы, төрле тармаклардагы эшчәнлеге, фокустагы кебек, аның әсәрләрендә гәүдәләнеш тапкан. Аны дөньяга әдәби иҗаты танытты. Шуңа күрә Айтматов хакында сүз барганда, без, телибезме — теләмибезме, аның әсәрләре турында азмы-күпме фикер әйтергә бурычлыбыз. Шунысын да искәртик: аның әсәрләре дөньяның 200 ләп теленә тәрҗемә ителеп, мең мәртәбәгә якын нәшер ителгән. Тираж саны, мөгаен, 100 миллион данәдән артып киткәндер. Ч. Айтматов хакында дөньяның 47 телендә 328 китап, 400 гә якын фәнни-популяр мәкалә басылып чыккан. Мактану дип кабул ителмәсен: бу әдип иҗаты турында тәүге сүзләрнең берсен татар телендә моннан илле еллар элек без фәкыйрегез (ул вакытта мәктәп директоры) әйткән иде. «Гади кешене олы итеп» дип исемләнгән ул язма «Казан утлары» журналының 1966 елгы 6 нчы санында басылып чыкты. Билгеле бер вакыт аралыгыннан соң үз язмаңа да шактый объектив, башка кешенекенә караган кебек күз саласың. Күп еллар узса да, ул мәкаләдәге фикерләр һич тә искермәгән икән. Ч. Айтматов әсәрләренең татар телендә басылуы хуплана, алардагы тормышчан геройларның, вакыйга-күренешләрнең укучыны дулкынландыруы, рухи яктан тәрбияләве искәртелә.

Узган йөзнең 50 нче еллар башында әдәбиятка килеп, ярты гасырдан артык әдәби иҗат белән шөгыльләнгән Ч. Айтматов, барыннан да элек, проза остасы иде. Ул — күп санлы хикәяләр, повесть-бәяннар, романнар авторы.

Алар арасында аеруча «Җәмилә», «Дөя күзе», «Кызыл яулыклы гүзәлкәем», «Анам кыры», «Бәхил бул, Гөлсары», «Беренче мөгаллим», «Бер көн — бер гомер», «Белое облако Чингисхана», «Плаха», «Пегий пес, бегущий краем моря», «Когда падают горы (Вечная невеста)» әсәрләре мәшһүр. Аларның күпчелегендә илнең совет чорындагы тормышы гәүдәләнеш тапкан. Автор еш кына хәзерге заман тематикасына элекке чорлардагы вакыйга-хәлләрне, легенда-риваятьләрне дә табигый рәвештә кертеп җибәрә. Мәсәлән, «Чыңгызхан өстендәге ак болыт» бәянында (1990) Сталин чорында коточкыч җәза-михнәтләргә дучар ителгән Абуталип Куттыбаев язмышы гәүдәләнә. Ул, нахакка кулга алынып, гаиләсеннән, балаларыннан аерылган. Тикшерүче Тансыкбаев аны газаплаудан тәм таба, канәгатьләнү ала. Шушы уңай белән әсәргә Чыңгызхан турындагы легенда кертеп җибәрелә. Ул — җиһангир, буйсындыручы. Аның әмерен үтәмичә балалы булган ир белән хатынны Сталинга охшашлы бу зат җәзалап үтертә. Тормыш канунына, мәхәббәткә, нәсел дәвамчанлыгына каршы булган бу гайре гамәле өчен бу җиһангир Тәңре тарафыннан иңдерелгән бәхет-дәүләт символыннан — «ак болыт»тан мәхрүм ителә. «Когда падают горы...» романында туй алдыннан мәкер аркасында мәңгелеккә аерылган кияү белән кәләш турында риваять китерелә. Кошка әверелгән кыз урман-тауларның әле бер, әле икенче җирендә елаган тавышын ишеттерә. Бу легенда әсәрнең төп каһарман Арсен Саманчин язмышына да аваздаш. Романның ике исем белән аталуы да юкка гына түгел.

Ч. Айтматов әсәрләренең сюжеты тышкы вакыйга-хәлләрнең киеренкелегенә корылмаган. Ул, иң беренче чиратта, геройларның уй-кичерешләре, рухи дөнья каршылыклары аша укучының игътибарын җәлеп итә. Автор, ничектер, гадәти нәрсәләрне, күнегелгән эш-гамәлләрне дә, гомумән, яшәеш-тереклеккә хас булган фәлсәфи төшенчәләр белән бәйли белә. Юкка гына галим-тәнкыйтьчеләр аны әдип-философ дип атамыйлардыр. Фәлсәфилек Ч. Айтматовның иҗади эволюциясендә көчәйгәннән-көчәя бара. Бу сыйфат аеруча аның соңгырак дәвер роман-бәяннарына хас.

Ч. Айтматов социаль иерархиянең түбәнрәк баскычларында торган кешеләр турында язарга ярата. Алар арасында Җәмилә, Дүшән, Танабай Данияр, Тулганай, Әбуталип кебек гап-гади кешеләр төп урынны алып тора. Әмма автор аларның рухи дөньясын, кайгы-шатлыкларын тирән һәм үтемле итеп, күңелләрне тетрәндерерлек югарылыкта тасвирлап бирә. Шуның нәтиҗәсендә теләсә нинди милләт, социаль катлам укучысы Ч. Айтматов әсәрләрендә үзенә авараздаш якларны таба, гадәти кыргыз, гадәти чабан образларында гомумән инсаннарга хас сыйфатларны күрә, тоя.

«Җәмилә»не 1959 елда француз теленә тәрҗемә иткән Луи Арагонның бу повестьны «мәхәббәт турындагы иң гүзәл әсәр» дип атавы күпләргә мәгълүм. Бөек француз әдибенең бу фикерен Ч. Айтматов башка әсәрләре белән дә кат-кат раслады. Ул, Низами, Котб, Харәзми, Нәваи кебек, мәхәббәтнең бөеклеген, яшәеш-тереклеккә хас булган гомуми сыйфат икәнлеген җанлы, тормышчан образларда сурәтләде. Аның фикеренчә, «мәхәббәт — күңел балкышы» («озарение души»), «галәм бүләге», «мәңгелек белән тоташтыручы энергия». Әдип бу изге хисне чәчмә юллар белән шагыйранә югарылыкта гәүдәләндерә. Аеруча ул тудырган хатын-кыз образлары күңелдә уелып кала.

Ч. Айтматов мифологиядә һәм фольклорда, аеруча «Манас» дастанында, халык ышануларында туплаган иҗади-эстетик казанышларны файдаланып, үз әсәрләрендә кеше һәм табигатьне үзара тыгыз бәйләнештә тасвирлауга җитди игътибар итә. Аның иҗатында таулар һәм елгалар, атлар, дөяләр һәм барслар җанлы образлар рәвешендә әсәр тукымасында урын ала, инсаннарның язмышында, эш-гамәлендә мөһим роль уйный. Ч. Айтматов язмаларында аеруча дала образы мөһим урынны били. Ул, ничектер, киңәшче, таяныч, терәк һәм башка бик күп төрле вазыйфалар алып, әдип иҗатында универсаль, символик яңгыраш ала. Язучының күп кенә әсәрләрендә соңгы дәвер атрибуты булган тимер юл, дала аркылы узып торучы поездлар хәрәкәт-динамиканы, вакыт агышын, кешеләр язмышын, яшәү-үлем фәлсәфәсен гәүдәләндерүдә әһәмиятле роль уйный.

Ч. Айтматов, — чын мәгънәсендә, инсаният җырчысы. Күпгасырлык шәркый традицияләрне, тормыш тәҗрибәсен дәвам итеп, баетып, ул адәм балаларының бәхетле, үзара дус, тату яшәргә тиешлегән раслый, намус, вөҗдан, гаделлек төшенчәләренең һәрчак актуаль булуын искәртә; инсаннарны бозыклыктан, явыз гамәлләрдән, манкортлыктан, хәтерсезлектән сакларга, алардан коткарырга омтыла. Әдип безнең күз алдына олуг Мөгаллим, бөек Остаз, Акыл иясе рәвешендә килеп баса.

Ч. Айтматов әсәрләренең тел-стиле искиткеч бай, тыгыз, сыгылмалы. Аларда күп төрле чагыштыру-сурәтләр, оригиналь детальләр тулып ята. Мәгълүм ки, Ч. Айтматов аерым әсәрләрен генә кыргызча язган. Аның күпчелек роман-бәяннары турыдан-туры урыс телендә иҗат ителгән. Әмма әдипнең «урыс теле» ул гаҗәеп үзенчәлекле күренеш. Аның төрки тел стихиясе, образлы фикерләве белән табигый бәйләнеше нык сизелеп тора. Бу мәсьәләне махсус өйрәнү кызыклы гына нәтиҗәләргә китерер иде.

Ч. Айтматов — совет җирлегендә алырга мөмкин булган күпчелек бүләк-премияләргә ия зат. Ул, мөгаен, Ленин премиясе лауреатларының иң яше (35 яшь) булгандыр. Аның «Правда» гәҗитенең үз хәбәрчесе, «Иностранная литература» журналының баш мөхәррире, СССР Верховный Советы депутаты һәм башка җаваплы вазыйфаларны башкаруы да мәгълүм. Ч. Айтматов — халыкара масштабта да танылган әдип. Ул Җәвахарлал Неру исемендәге бик тә дәрәҗәле премиягә ия. 2007 елда Ч. Айтматов Төркиядәге бер форумда «дөньяның иң бөек әдипләренең берсе» дип тә игълан ителә. Хәтта аны Нобель бүләгенә дә тәкъдим итәргә җыенганнар... Әмма көтелмәгән үлеме бу ниятнең гамәлгә ашуына мөмкинлек бирми.

Ч. Айтматов әсәрләре нигезендә куелган спектакльләр, кино һәм телефильмнар, сәнгать әсәрләре  дә берничә йөздән артып китәдер.

## II

Ч. Айтматовның 85 еллыгына багышланган бәйрәм чаралары Мәскәүнең Чит илләр китапханәсендә әдипкә бюст-һәйкәл ачылудан башланып, бераздан Казанга күчте. 25 нче октябрьдә Казан федераль

университетында «Мәдәниятләрнең үзара бәйләнешендә Чыңгыз Айтматовның әдәби дөньясы» темасына зур халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. «Мир» кинотеатрында бөек әдипкә мөнәсәбәтле кинофильмнар барды. Бу чараларда Кыргызстаннан бик вәкаләтле делегация катнашты. Аның составында мәдәният һәм спорт министры Солтан Раев, Кыргызстанның Рәчәйдәге илчесе Болат Җунысов, атаклы режиссер, СССРның халык артисты Болат Шәмшиев, Кыргызстан Милли фәннәр академиясенең вице-президенты (безнең күптәнге танышыбыз) Абдуллаҗан Акматалиев, бөек әдипнең бертуган сеңлесе, йөз-кыяфәте белән абыйсының күчермәсе, Роза Айтматова һ. б. бар иде. Делегация Җөмһүриятебез җитәкчеләре, шул исәптән М. Шәймиев тарафыннан да кабул ителде. Кыргызстан кунаклары белән очрашуның иң җылысы, иң истәлеклесе, мөгаен, Республика Милли китапханәсендә булгандыр. Бу кичәдә безнең күпләгән әдипләребез, галимнәребез дә катнашты (Без фәкыйрегезгә дә бу очрашуда чыгыш ясарга туры килде). Кичәдә Газинур Моратның «Хөрмәтле Чыңгыз әкә ядкәре» исемле үз шигырен бик тә тәэсирле укуы күпләрне тетрәндерде. Анда бөек әдипнең әби-бабалары төбәгенә — Кукмарага 2008 елда кайтырга чыгып та, Казанда туктап калуы (авыруы...) олы үкенеч, сагыш хисләре аша белдерелә.

... Кайтып җитәсе лә иде юкса,
Сәфәренә чыкса иртәрәк.
Төп нигезгә юллар, һай, урау шул,
Ул гел ерак, һәрчак читтәрәк.

Йөз чакрымнар гына иде юкса,
Казан белән Күк Тау (ягъни Кукмара. — Х. М.) арасы.
Төп нигезгә кайтып баш орырга
Гел кичегә адәм баласы.

Бер атлам юл калган иде юкса,

Шуны узу язсын кемгә дә.

Кукмарага кайтып бара Чыңгыз

Гасырдан да озын көннәрдә.

(Мәдәни җәмга. — 1. 11. 2013)

Ч. Айтматовка багышланган бәйрәм Татарстанның вакытлы матбугатында, электрон чараларында шактый тулы чагылдырылды. [Киләчәк кешесе//Ватаным Татарстан. — 29. 10. 2013; Чыңгыз Айтматов — уртак горурлыгыбыз//Мәдәни җомга. 1. 11. 2013 һ. б.].

Мәгълүм ки, бөек әдипнең әнисе ягыннан нәсел шәҗәрәсе Балтач районының Борбаш һәм Кукмара төбәгенең Мәчкәрә авылларына барып тоташа [Бу хакта җентеклерәк мәгълүматлар Роза Айтматованың «Белые страницы истории: Мои воспоминания (Бишкек, 2013. — 268 с.), Гөлназ Галимҗанованың «Чыңгыз Айтматов: гаилә серләре» мәкаләсендә («Хезмәт таңы» гәҗите. Кукмара. — 5. 09. 2008) һәм Мәчкәрә, Кукмара музейларында бар]. Бу — күпбуынлы Ишмән-Үтәмешевләр шәҗәрәсе. Борбаш, Мәчкәрә зыяратларында бу нәселгә кагылышлы шактый гына каберташлары хәзергәчә сакланган. Чыңгызның әнисенә мөнәсәбәтле шәҗәрәнең бер тармагын, гадәттә, Көчек улы Туктаргалидән башлыйлар. Аннан Ишмән (Ишмөхәммәд. 1610 елда туган бу зат әүвәл Борбашта яшәп, аннан Мәчкәрәгә күчеп килә) — Йосыф — Хәлим — Габдерәшит — Гайсә — Габделвәли —Хәсән — Хәмзә... чылбыры килә. Чыңгызның бабасы Хәмзә Хәсән углы Габделвәлиев (якынча 1850—1932 еллар) Мәчкәрәдә яши, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Өйләнә. Исмәгыйль исемле баласы була (Кукмара музее директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшина фикеренчә, Исмәгыйль шул тирәләрдә тыйнак кына яшәп, бакыйлыкка күчә. Бала-чагасы булмый). Хәмзә Габделвәлиев, ни сәбәптәндер, гаиләсен калдырып, үзенең бертуганы Әхмәтгали һәм Галия белән берлектә, 1870—80 елларда хәзерге Кыргызстанның Каракүл (Пржевальск) тирәсендәге Аксу бистәсенә килеп төпләнә. Күренекле сәүдәгәр булып таныла, зур-зур кибетләр тота. Биредә Хәмзә Габделвәлиев

икенче мәртәбә өйләнә. Үзеннән шактый яшь булган хатыны Газизәбану — тумышы белән Семипалат каласыннан, затлы татар гаиләсеннән. Ул — күренекле рухани, химаяче Верный (хәзерге Алматы) шәһәренең бердәнбер «беренче гильдий купецы» Исхак Хаҗиның (1830—1911) балдызы. Исхак Хаҗи Хәмзә — Габделвәлиевнең кардәше («дядя»се), аны Кыргызстан тарафларына чакырып китерүче зат. [Шунысын да искәртик: Газизәбану — Казакъстан белән шактый еллар җитәкчелек иткән Д. Кунаевның әнисе белән бер нәселдән]. Әйтүләренә караганда, Газизәбану — бик тә чибәр, сабыр холыклы, тәрбияле кеше була, ире Хәмзә белән тату, килешеп яшиләр. 8 балалары була. Шәриф, Зәйнәп, Сабир, Мөхәммәд, Гөлша (?Гульша), Әсма, Нәгыймә, Габдулла [Игътибар итегез: барысы да диярлек татарда киң таралган исемнәрне йөртә]. Һәммәсе дә әүвәл мәдрәсәдә, аннан башка төр уку йортларында укып, белемле, һөнәрле булалар. Сабир, мәсәлән, Иж-Буби мәдрәсәсен төгәлли, аннан Ташкентта сәүдә уку йортында — «коммерческое училище»дә белем ала. Берлинда укуы, төрле чит мәмләкәтләрдә булуы да мәгълүм. Газизәбану һәм Хәмзә Габделвәлиевләр гаиләсендә татар һәм ислам рухы, зыялылык хөкем сөрә. Бай, шәхси китапханәләре дә була. Сабир үз дус-ишләрен җыеп, еш кына татарча спектакльләр куя. Аларда төп рольләрне Нәгыймәнең башкаруы да билгеле. Бу гаилә үзенең бакчачылык һөнәре белән дан тота. Хәмзә Габделвәлиев күптөрле алма, җимеш агачлары үстерә. Хәзер дә Каракүл тирәсендәге бер автобус тукталышының «Габделвәлиев бакчасы» исемен йөртүе тирән мәгънәле.

Октябрь инкыйлабыннан соң Габделвәлиевләрнең күпчелек мал-мөлкәте дәүләт карамагына алына. Төрле эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә гаилә әгъзалары төрлесе төрле якка тарала башлый. 1930 елда Сабир әти-әнисен Ташкентка алып китә. Бер елдан соң Газизәбану һәм 1932 елда Хәмзә фани дөньядан китеп баралар; Ташкентта җирләнәләр дә.

Габделвәлиевләрнең җиденче баласы — Нәгыймә (7. 12. 1904 — 10. 08. 1971) Каракүлдә туа, бик тә җитү, мул тормышлы, укымышлы гаиләдә милли

тәрбия алып үсә. Әүвәл татар мәдрәсәсендә укый. Аннан Каракүлдәге хатын-кызлар гимназиясен тәгәлли. Татар, кыргыз, урыс телләрендә иркен укый, сөйләшә. Кызы Роза истәлекләренә караганда, ул бик оста, мавыктыргыч итеп сөйли торган була (43 б.). Әдәбиятны, аеруча татар сүз сәнгатен ярата.

Мәгълүм булганча, Октябрь инкыйлабына, тәгәлрәге узган гасырның 30 нчы елларына кадәр Урта Азиядә, шул исәптән Кыргызстанда да татар мәгарифе, мәдәнияте киң таралыш һәм җирләнеш таба, аеруча Тукай әсәрләре бик яратып укыла. Бу хакта Чыңгыз Айтматовның үз фикерләре дә кызыклы.Ул үзенең Тукай белән «соклануын», аның талантына һәм мирасына «мөнәсәбәтле» булуын, аның «дәвамчысы» икәнлеген искәртә («Я движим чувствами причастности к таланту и наследию Габдуллы Тукая»)... Алга таба ул болай ди: «Все тюркоязычные народы испытали поистине неизгладимое, по сей день свято хранимое воздействие, впечатление от творчества Габдуллы Тукая.

Нет таких людей в нашем крае, среди тюркоязычного населения Средней Азии, которые не были бы знакомы с его творчеством. Ибо Тукай был проводником европейского и русского революционного художественного мышления именно в то время, когда наши народы ещё не освоили в той степени русскую культуру и русский опыт, который они освоили позже». Шагыйрьнең талантына, иҗатына сокланып, ул мондый сүзләрне дә әйтә: «... иногда думается, что он прожил  не 27, а может быть 270 лет на свете», что «Тукай был и есть самый великий татарин во всей татарской истории» [Чингиз Айтматов. Удивительная зрелость таланта/Габдулла Тукай: Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта. — К.: Татар. кн. изд.-во, 1979. — С. 219—220].

Нәгыймә «икенче баскыч» совет мәктәбендә дә укый. 1925 елда ул медицина техникумына керергә тели. Әмма «бай нәселеннән» дип аны бу уку йортына алмыйлар. Шуннан ул стенографистлар курсына укырга керә һәм аны тәмамлагач, комсомолның өлкә комитетында машинистка булып эшли

башлый. Шушы чорда ул Терекул (Түрәкол) Айтматов белән таныша. Тиз арада гаилә дә корып җибәрәләр. 1928 елда Шекер авылында уллары Чыңгыз дөньяга килә, аннан — Илгиз. Нәгыймә ханым игезәк бала да таба. Аларга Рево һәм Люция исемнәре бирәләр. Әмма алты айдан соң Рево үлеп китә. 1937 елда төпчек балалары — Роза туа.

Терекул Айтматов (1903—1938) тумышы белән хәзерге Кыргызстанның Талас өлкәсе Шекер авылыннан, «кытай» дип йөртелгән ырудан. Әтисе Айтмат — төрле һөнәрләр иясе — хәлле генә тормыш (1920 елда вафат була) алып бара. Терекул әүвәл туган авылындагы мәдрәсәдә укый. 1914—1917 елларда үзләреннән ерак булмаган Әүлия-Атадагы (Казакъстандагы бу шәһәр бераздан Җамбул, ә хәзер Тараз исеме белән йөртелә) урыс — җирле халык («Русско-туземная») мәктәбендә белем ала. 1918—1919 елларда шул ук шәһәрдәге «хезмәт» мәктәбендә, реаль училищеда укый. 1921—1924 елларда Мәскәүдәге Коммунистик университет студенты (КУТВ — Коммунистический университет трудящихся Востока»). 1935—1937 елларда Мәскәүдә ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм курслары, Кызыл профессура институты тыңлаучысы. 1925 елның мартыннан 1937 елның 10 декабренә кадәр ВКП(б) әгъзасы. Урыс, кыргыз телләрен камил, татарча да яхшы белә. Гарәп, латин, кирилл графикаларында иркен укый, яза. Терекул Айтматов — Кыргызстанның күренекле партия һәм дәүләт эшлеклесе. Бик күп төрле урыннарда эшли, җаваплы вазыйфалар башкара. Мәсәлән, 1929 елда ул Кыргызстанның сәнәгать һәм сәүдә наркомы, 1929—1931 елларда Республика Халык хуҗалыгы Үзәк Советы рәисе, 1934—1935 елларда ВКП(б)ның Кыргызстан Республикасы Комитетының икенче секретаре... Бу чорның күп кенә кешеләре кебек, Терекул Айтматов та «советка каршы көрәштә», «милләтчелектә» гаепләнеп, 1937 елның 1 декабрендә Мәскәүдә кулга алына. Аны этап белән Фрунзе (хәзерге Бишкек) каласына озаталар 1938 елның 5 ноябренда атып үтерелә... 1957 елның 15 июль карары нигезендә реабилитацияләнә. Терекул Айтматовның үлемен гаиләсенә, якыннарына

әйтмиләр. Чыңгызның әнисе 1939 елда шушындый эчтәлекле рәсми җавап ала: «Объявите гражданке Айтматовой Нагиме... что её муж осужден правильно и выслан в дальние края без права переписки» (Роза Айтматова. Белые страницы..., с. 205). Нәгыймә ханым, 4 бала әтиләре, бәлкем, кайтыр дип ике дистә еллап көтәләр. Бары 1957 елның августында гына чын хакыйкать ачыла.

Ч. Айтматовның «Анам кыры» бәянындагы эпиграф шушындый сүзләр белән башланып китә: «Әти, кабереңнең кайда икәнен белмим». Ул бары тик 1991 елда гына мәгълүм була. Бишкек тирәсендәге Чон-Таш дигән урында элеккеге кирпеч заводы чокырларында 1938 елда атып үтерелгән 137 кешенең сөякләре табыла. Алар арасында Терекул Айтматов та була. Фаҗига булган урында 1991 елда мемориал комплекс ачыла. Ч. Айтматов тәкъдиме белән Чон-Таш каберлегендә Ата-Бейете» (ягъни «Аталар каберлеге») исеме бирелә. Бөек әдип үзе дә шунда җирләнә.

Нәгыймә ханымның, Айтматовлар гаиләсенең язмышы күтәрелү-төшүләрдән, рәхәт-михнәтләрдән гыйбарәт. Татар кызының ата йортындагы мул һәм кайгысыз тормышы; Октябрь инкыйлабыннан соң «бай баласы» дигән ярлык тагылу; дәрәҗәле партия-хөкүмәт хезмәткәренең тормыш иптәше, аннан «халык дошманы»ның хатыны. Кая барса да — кагылу, сугылу, хокуксызлык; эш таба алмыйча, каңгырып йөрүләр, йортсызлык — кеше өстендә торулар. Мондый исемнәрдән, кырын карашлардан Нәгыймә ханым бары улы Ленин премиясе лауреаты булгач кына тәмам котыла. Әдипнең сеңлесе Роза Айтматова истәлекләрен укыганда бу Ананың катлаулы язмышын кичереп, күңелләр тула. Нинди генә кыенлыклар булса да, тол калган Нәгыймә ханым балаларын тәрбияләүгә, укытуга бөтен көчен, сәламәтлеген бирә. 4 баласы да югары белем алып, тормышта үз урыннарын табалар. Өлкән улы гаиләдә әнисенең төп таянычы, терәге, ярдәмчесе була.

Мәгълүм ки, Чыңгыз тәүге ике сыйныфны Мәскәүдә укый. Аннан — туган авылы Шекердә. Сугыш чорында укуын туктатып, булачак әдип авыл советы секретаре, тракторда прицепщик, финагент булып эшли. Өч елдан соң

Чыңгыз район үзәгендәге (Покровкадагы) мәктәптә укуын дәвам итә. Сигезенче сыйныфны бетергәч, Җамбул (Тараз) зооветеринария техникумында укый. Гаиләгә ярдәм итәм дип, эшләргә була. Әмма әнисенең озак-озак үгетләвеннән соң, 1949 елда Фрунзедагы авыл хуҗалыгы институтында укый башлый. Тулай торакта яши. 1953 елда, институтны кызыл дипломга тәгәлләгәч, Чыңгыз республика башкаласыннан ерак булмаган Чон-Арык авылындагы терлекчелек буенча фәнни-тикшеренү институтының тәҗрибә фермасында зоотехник булып эшли башлый. Фатир да бирәләр. Шунда ул үз янына әнисен һәм туганнарын да алдыра. Фәнни-тикшеренү институтында Чыңгыз тырышып өч елдан артык эшли, фән белән дә шөгыльләнә. Үзенең теләге булса да, «халык дошманы»ның улы дип аны аспирантурага алмыйлар. 50 нче елларда Чыңгыз Айтматов ныклап әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. Аның алга таба тормышы (Мәскәүдә әдәбият курсларында укуы; төрле редакцияләрдә эшләве һ. б.) күпләргә мәгълүм. Шуңа күрә биредә аларга тукталып тормыйбыз. Шунысын да хәтергә төшерик: әдипнең әсәрләрендә авторның үз тормышы, шәхси кичерешләре дә шактый тулы гәүдәләнеш тапкан.

Чыңгыз Айтматовның тормышында, әдәби һәм шәхси үсешендә Хәмзә кызы Нәгыймәнең роле искиткеч зур. Үз әсәрләрендә олы җанлы, бай табигатьле күркәм хатын-кыз образларын тудыруда әдип, һичшиксез, әнисенең дә күп кенә сыйфатларын, эш-гамәлләрен файдаланган.

Истәлекләрдән Нәгыймә ханымның сугыш чорларында ук авырый башлавы искәртелә. Аяк тамырлары шешә, астма белән интегә. 1962 елда ананың исәнлеге бик тә начарлана. Табиблар аның гомере бетеп баруын искәртәләр. Чыңгыз бәргәләнә, әллә кайлардан тиешле дарулар таба. Шушы вакытларда ул үзенең атаклы «Анам кыры» бәянын яза, үз сүзләре белән әйткәндә, «әнисе хакында нәрсә әйтергә теләсә,— барысын да белдерә» («выразил все, что хотел сказать о своей матери») (Р. Айтматова. Белые страницы..., с. 214). Ул бу әсәрен әти-әнисенә багышлый. Анда мондый юллар бар: «... Әни, син безнең дүртебезне дә тәрбияләп үстердең. Сиңа,

Нәгыймә Айтматовага, багышлыйм бу әсәремне».

Нәгыймә ханым үз балаларына, оныкларына, туган-тумачаларына гына түгел, ә башкаларга карата да ярдәмчел, ачык йөзле булган. Ул 1971 елның 10 августында Фрунзе  хастаханәсендә соңгы сулышын ала. Бу хәлнең шаһиты булган Чыңгыз үксеп елый... Нәгыймә ханымны соңгы юлга дөнья кадәр халык озата. Бу моңа кадәр күрелмәгән җеназа процессиясе була. Бөек Ананың вафатына да инде шактый еллар узды. Әмма халык бу игелекле затны онытмый. Кыргызстанда аның исемендә аллея-урамнар булу — шуның бер билгесе.

*  *  *

Нәгыймә ханым, гәрчә бик теләге булса да, дөнья мәшәкатьләре, авыруы аркасында әтисенең туган якларына кайта алмый. Кызганыч ки, улы Чыңгыз белән дә шушы ук язмыш кабатланды. Дөрес, ул, әнисеннән үзгә буларак, Казанга кат-кат килде, татар әдипләре, Татарстан җәмәгатьчелеге белән күп мәртәбәләр очрашты. Гомеренең ахырына таба нәсел шәҗәрәсе белән кызыксынуын тагын да көчәйтте. 2008 елның маенда әнисе, әби-бабалары хакында документаль фильм төшерү нияте белән Казанга килде, бүген-иртәгә Балтач, Кукмара тарафларына Татарстан президенты М. Шәймиев белән берлектә барам дип торганда кинәт авырып, аны тиз генә Мәскәү аша Алманиягә алып киттеләр. Һәм бөек әдип шунда мәңгелеккә күзләрен дә йомды... Нишлисең бит, тәкъдир шулай язгандыр. Г. Морат әйтмешли, «Төп нигезгә кайтып баш орырга Гел кичегә адәм баласы».

Куаныч ки, кукмаралылар Габделвәлиев һәм Айтматовларны онытмыйлар, аларны һәрчак истә тоталар. Төрле кичәләр, мәдәни-мәгърифәти чаралар үткәрелә. Район һәм җөмһүриятнең көндәлек матбугатында да кызыклы материаллар басылып тора. Район үзәгендәге татар гимназиясе Ч. Айтматов исемен йөртә. Бөек әдип, аның нәсел-нәсәбен өйрәнү эшенең үзәгендә Кукмара төбәк музее директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшина тора. Заманында бу тынгысыз затның Ч. Айтматов, аның туганнары, якыннары белән очрашуы, аларга Ишмән шәҗәрәсен һәм башка

төр материаллар бирүе дә мәгълүм. Район музеенда, Мәчкәрә мәктәбендә Үтәмешев-Айтматовларга кагылышлы бай экспонатлар тупланган.

Кукмаралылар бөек әдипнең 85 еллыгына да бик ныклап әзерләнгәннәр иде. Әмма янә «кызганыч ки», «үкенеч ки» сүзләрен кулланырга туры килә: ни сәбәптәндер, Кыргызстанның мәртәбәле делегациясе, аеруча Роза ханым Айтматова Кукмарага килә алмады (Янә бер тәкъдирнең шаяруы).

Кукмарада 27 октябрьдә бәйрәм чараларында без фәкыйрегезгә һәм профессор Фоат Галимуллинга катнашырга туры килде. [Моның өчен район хакимиятенә, мәгариф идарәсенә рәхмәтлебез. Шунысын да искәртим: кукмаралылар үз якташлары Фоат әфәндене зурлыйлар, хөрмәт итәләр икән]. Әүвәл район үзәгендә бик тә эчтәлекле фәнни-гамәли конференция — «Айтматов укулары» үткәрелде. Анда район укытучылары һәм укучылары, мәдәният хезмәткәрләре генә түгел, республиканың башка төбәкләреннән дә вәкилләр бар иде. Мәскәүдән зур галим, техник фәннәр докторы, академик Илдар Рөстәм улы Үтәмешев һәм аның җәмәгате дә катнашты. Мәгълүм ки, бу мөхтәрәм зат — бөек әдипнең нәселдәше. Аның этисе Рөстәм Исмәгыйль улы (1926 елгы) — космонавтикага, Ю. Гагаринны очышка әзерләүгә зур өлеш керткән мәшһүр галим. Шунысы куанычлы: Кукмарадагы гыйльми-гамәли чарада олимпиадада җиңеп чыккан берничә укучы да чыгыш ясады. Аларның докладларын тыңлап, без сөенеп утырдык.

Айтматов чараларының иң күңеллеләренең берсе, мөгаен, Мәчкәрәдә булгандыр. Ул — элек-электән татар дөньясының мәшһүр гыйлем-мәгърифәт төбәге. Бу авылның XVIII гасыр урталарында ук эшли башлаган атаклы мәдрәсәсендә Г. Курсави, Х. Әмирхан, Шиһабеддин Мәрҗанинең этисе, М. Тукаев һәм башка бик күп билгеле затлар белем ала. Үтәмешевләр төзеткән мәчет (1791) үзенең зурлыгы, архитектурасы белән бүген дә игътибарны җәлеп итә (Хәзер ул Татарстан президенты ярдәме белән төзекләндерелә). XIX гасырның икенче яртысында корылган «Үтәмешевләр йорты» бүген дә авылны бизәп тора.

Гөлназ Галимҗанованың бөек әдипнең «гаилә серләре» турындагы

язмасында («Хезмәт таңы». — 5. 09. 2008) мондый юллар бар: «Чыңгыз Айтматов журналист Мәгъсум Гәрәев белән 2000, 2006 еллардагы очрашуларында: «Мин бит татар малае, татар язучысы! Миндә татар каны ага, ханнар гены саклана». Бу юллар Мәчкәрәнең мәктәп музеендагы стендта да бар. Очрашу кичәсендә дә бу сүзләр кат-кат яңгырады. Бәхәсләшмим, бәлкем, үзара әңгәмә вакытында Ч. Айтматов бу сүзләрне әйткәндер. Әмма Ч. Айтматовның, гәрчә әнисе ягыннан татар булса да, теге яки бу дәрәҗәдә татар тәрбиясе алса да, кыргыз язучысы булуын онытырга ярамый. Ул үзенең искиткеч бай иҗатында барыннан да элек кыргыз халкының рухын, яшәү рәвешен, табигатен гәүдәләндергән. Бу уңай белән Рафис Корбан «Тәкъдир» шигырендә болай ди:

Татар кызы тапкан аны,
Безнең Казан арты кызы.
Кем дип үзен атарга соң?
Татармы ул, йә кыргызмы?

Ә язуы башка телдә,
Язды урыс телендә ул.
Кыргызның йолдызы булды
Шушы урыс илендә ул.

Язды кыргыз язмышларын —
Кыргыз кызын, кыргыз картын.
Бар галәмгә бәян итте
Үлеп барган кыргыз атын.

(Мәдәни җомга. — 11. 10. 2013)

Ч. Айтматов үзенең язмаларында татарга мөнәсәбәтле булуын бик телгә алмый. Әсәрләрендә дә татар персонажлары, татар тормышы күзгә ташланмый. Моның, әлбәттә, үзенең билгеле бер сәбәпләре булгандыр. Болар хакында М. Госмановның «Бирелмичә калган сораулар (Сорауларны Ч.

Айтматовка бирергә уйлаган идем)» язмасында (Казан утлары. — 2009. — № 5. — 102—119 б.) кызыклы гына фикер-күзәтүләр бар. Совет чынбарлыгы, XX йөз тормышы өчен Ч. Айтматовның милли пландагы эш-гамәле һич тә гайре табигый түгел. Хәтта этник яктан яртылаш түгел, тулы татар булганнар арасында да, башка кавемнәргә хезмәт итеп, урыс, башкорт, казакъ, үзбәк... әдип-галимнәре, сәнгать әһелләре булып танылучылар шактый. Мондыйлар хәтта Казанда, Татарстанда туып үскәннәр, әти-әнисе татар зыялысы (язучысы...) булганнар арасында да очрый. Шуңа күрә, җәмәгать, гәрчә ул кыргыз-татар улы булса да, без Ч. Айтматовны татар әдибе итәргә тырышмыйк. «Кыргыз язучысы» дигәндә дә ул безнең өчен якын, үз. Аның иҗаты без татарларны да дулкынландыра, сафландыра, игелекле яшәргә өйрәтә. Шул вакытта «мондый әсәрләрне татар кызы Нәгыймәнең улы язган бит» дип горурланып та куярга була. Янә бер хакыйкатьне онытмыйк: күпгасырлык тарихы булган татар сүз сәнгате, Чыңгыз Айтматовсыз да, зур әдәбият. Анда Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Кутуй, Г. Бәширов, Ә. Еники, А. Гыйләҗев һәм кайбер башка прозаикларның «Җәмилә», «Анам кыры», «Беренче мөгаллим» дәрәҗәсендәге (хәтта артыграк та) әсәрләре бар. Өстәвенә без, ягъни, мәсәлән, татар, үзбәк, казакъ, кыргыз... — барыбыз да гомуми бер кавем — төрки — балалары. Шулай булгач, Ч. Айтматов та билгеле бер дәрәҗәдә һәммәбез өчен дә уртак булган төрки әдип, М. Шәймиев сүзләре белән әйткәндә, «уртак горурлыгыбыз».

**III**

Мәскәүдә Татарстанда башланган Айтматов чаралары ноябрь башында Казакъстанда дәвам итте. Бу табигый һәм мантыйкый да. Чөнки казакълар һәм кыргызлар — элек-электән тыгыз аралашып гомер кичергән бик тә якын булган кардәш кавемнәр. Ч. Айтматов күп мәртәбәләр Казакьстанда була. Әле хәзер дә хәтердә: 1997 елның сентябрендә Алматыда Мохтар Ауэзовның тууына 100 ел тулуга багышланган Халыкара конференциядә Ч. Айтматов казакъ-кыргыз мөнәсәбәтләре турында, «Абай» авторының үзенә нык тәэсир итүе хакында бик тә ялкынланып сөйләгән иде [Бу гыйльми чарада безгә дә

катнашу һәм Ч. Айтматов артыннан ук «Мохтар Ауэзов һәм татар әдәбияты» темасына доклад сөйләү бәхете ирешкән иде. Ахырда «чыгышыгыз әйбәт булды» дип Чыңгыз әкәнең кулны кысуы да истә калган].

Илнең башкаласы Астана шәһәрендә 6 ноябрьдә «Чыңгыз Айтматов һәм хәзерге төрки дөнья» дип исемләнгән зур халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Ул Казакъстан белем һәм фән министрлыгы, «Төрки академия» тарафыннан оештырылган иде. Бу гыйльми-мәдәни чара мәһабәт «Пирамида» корылмасының әкияти югары катында барды (Бу бина, мөгаен, Казаннныкыннан берничә мәртәбәгә зурраактыр. Аның икенче катын мең ярым кешелек искиткеч концерт-тамаша залы били). Конференция югары кимәлдә, бик яхшы оештырылган иде. Аның эшендә Казакъстанның күренекле әдипләре (Нурлан Оразалин, Мохтар Шаханов...), галимнәре (Турсынбәк Кәкишев, Сәйт Каскабасов, Әсим Гарифулла...), парламент депутатлары, җәмәгатьчелек катнашты. Шулай ук төрки дәүләтләрнең галимнәре, илчелек вәкилләре дә бар иде. Конференцияне «Төрки академия»нең президенты Шакир Ибраев ачты һәм алып барды. Бу гыйльми чарада, Азәрбайҗан Фәннәр Академиясенең вице-президенты, Низами исемендәге әдәбият Институты директоры, илнең парламент депутаты Иса Габибейли, Үзбәкстан профессоры Нәсимхан Рахманов, Кыргызстан Фәннәр Академиясенең вице-президенты Абдуллаҗан Акматалиев, Азәрбайҗан милли университетының кафедра мөдире, шагыйрь Рәмиз Әскәров (ул Г. Тукайны, Р. Миңнуллинны азәрбайҗанчага тәрҗемә итә. Казанда да булганы бар. Безнең әдәбиятны яхшы белә. Аның өчен «татар хатын-кызлары — дөньяда иң матурлары») һәм башкалар белән берлектә, без фәкыйрегез һәм Фоат Галимуллин дә чыгыш ясады. Фоат әфәнде, Ч. Айтматовны күп мәртәбәләр күргән кеше буларак, үзенең истәлекләре белән уртаклашты, бөек әдип иҗатын әдәби бәйләнешләр яссылыгында яктыртты. Мин исә үз докладымда, Ч. Айтматов феноменын ачыклап, әдипне татар дөьясына мөнәсәбәттә карарга тырыштым. Аның 1962, 1965, 1976, 1990 елларда татарча басылган китапларын да, әсәрләренең татар театрларында сәхнәләштерелүен (бу спектакльләрдә катнашкан берничә

артистка Г. Тукай бүләге бирелүен) дә, бөек әдипнең безнең халык тарафыннан яратып укылуын, хөрмәт ителүен дә, Казанда, Кукмара тарафларында Ч. Айтматов бәйрәменең югары кимәлдә үткәрелүен дә телгә алдым. Ахырда әдипнең 85 еллыгына татар телендә чыгарылган «Повестьлар» китабын һәм казакъ шигъриятенең классик вәкиле Магҗан Җомабаевның тууына 120 ел тулу уңае белән татар телендә басылган «Җан сүзе» җыентыгын да (төзүчесе, төп тәрҗемәчесе — Рәдиф Гаташ) күрсәттем. Болар, әлбәттә, публика тарафыннан бик җылы кабул ителде.

Конференциядәге доклад-чыгышларда Ч. Айтматовның бөеклеге, әсәрләренең заманга аваздаш булуы ассызыкланды. Чыңгыз Айтматовның төрки кавемнәрне берләштерүче, дөньяга танытучы гаять мөһим фактор булуына аеруча басым ясалды.

Алда әйтелгәнчә, Ч. Айтматовның әтисе — шәхес культы чорының корбаны. Шуны исәпкә алып, конференциядә катнашучыларны Астанадан 35—40 чакрымнар ераклыктагы музей-мемориаль комплекска алып бардылар. Ул шәхес культы корбаннары истәлегенә Казакъстан президенты Н. Назарбаев инициативасы белән корылып, 2007 елның 31 маенда рәсми рәвештә ачылган. Биредә заманында «Акмолинское отделение Карлага (Карлаг — 26)» булган. Бераздан аны АЛЖИР дип йөртә башлыйлар, ягъни «Акмолинский лагерь жен изменников Родины». Анда 8 меңнән артык хатын-кыз тоткынлыкта газап чиккән. Стендларда күпчелегенең исем-фамилияләре язылган, рәсем-сурәтләре куелган. Тоткыннар арасында элеккеге Советлар иленең күренекле хатын-кызлары була: җырчы Лидия Русланова, актриса Наталья Сац, язучы Галина Серебрякова, маршал Тухачевскийның сеңлесе, Майя Плисецкаяның әнисе, билгеле әдипләрнең, дәүләт һәм партия эшлеклеләренең хатыннары Гөлҗамал Майлина, Азиза Рыскулова һ. б. лар лагерь михнәтләрен кичерәләр. 70 татар хатын-кызының да биредә булуы искәртелә (Тикшерергә, ачыкларга иде: кемнәр икән алар) [Шунысын да искәртим: минем хатынның әнисе Рабига һәм үги әтисе — Семипалат татары Тәүфыйк Хәсәнҗанов та шушы тирәдәге Карлагларның

берсендә иза чигәләр]. Бу комплекста Казакъстанның XIX—XX йөзләрдәге сәяси тарихы, «Алаш» хәрәкәте дә гәүдәләндерелгән. Сакен Сәйфуллин, Магҗан Җомабаев кебек күренекле затларга багышланган стендлар да бар. Безне озатып йөрүче әдәбиятчы-галим, «Төрки академия»нең гыйльми секретаре, бик тә зыялы, ярдәмчел зат Каербәк Кеменгернең әби-бабалары да АЛЖИРда «кунак» булганнар икән. Бабасының рәсемен күреп, Каербек әфәнде бик дулкынланып та китте. Бу музей-мемориалны карагач, халкыбызның фаҗигале тарихын, хаксызга рәнҗетелгән язмышларны күреп, күңелләр тетрәнә, гаделсезлеккә каршы нәфрәт уяна, гыйбрәтле сабаклар аласың. Мемориалны карарга элеккеге СССРның төрле почмакларыннан, чит илләрдән туристлар күпләп килеп тора икән.

Конференциядә катнашучы кунакларга, шул исәптән безгә дә игътибар көчле булды, дүрт йолдызлы «King hotel»дә яшәдек [Рәхмәт хуҗаларга, аеруча төрки дөньяны комплекслы, нәтиҗәле өйрәнүче, күп кенә җитди хезмәтләр чыгаручы «Төрки академия»гә]. Шәһәрне дә күрсәттеләр. Астана ай үсәсен көн, ел үсәсен ай үсеп һәр килүгә матурлана тора.

Миннән аермалы буларак, Фоат Галимуллин Астанада беренче тапкыр икән. Аңа 2013 елда дөнья күргән «Төрки тәрбия» антологиясен һәм «Төрки дөньясы» дип исемләнгән бай эчтәлекле, затлы, күләмле (меңәр битле) китаплар бүләк иттеләр (Миндә инде алар бар иде). Фоат әфәнде дистәләгән килолы бу басмаларны, һич тә авырыксынмыйча, Казанга кадәр «рәхәтләнеп» алып кайтты. Мөгаен, алардагы гыйлем-мәгълүматны куллары, бармаклары аша да кайтып җиткәнче үзләштергәндер. Ул бу каланың гүзәллегенә тәмам хозурланып йөрде.

Ч. Айтматовның 85 еллыгын бәйрәм итү эстафетасын Астанадан Бишкек алды. Бу табигый да. Чөнки ул — бөек әдипнең асыл Ватаны. Кыргызстандагы 13—17 ноябрь форумына без дә чакырулы идек. Әмма бара алмадык. Анда катнашкан профессор Флюра ханым Сәйфуллина фикеренчә, Ч. Айтматов бәйрәме бик матур үткән. Аның кысаларында бөек әдипкә багышланган музей ачылган, «Түгәрәк өстәл», «Халыкара театр фестивале»

һәм башка бик күп төрле чаралар уздырылган.

Кыргызстанга бара алмауны әүвәл үкенеч кебегрәк кабул иткән идек. Әмма 17 ноябрьдәге Казан аэропортында Мәскәүдән килгән самолетның шартлавы, коточкыч һәлакәт «үкенеч» сүзенең урынлы булмавын искәртте. Бишкекка бару-кайту Мәскәү аркылы планлаштырылган иде. Әгәр дә безнең ният гамәлгә ашкан булса, без шул шартлаган очкыч белән кайтырга тиеш идек. Шөкер, Ходай Тәгалә безне афәт-һәлакәттән саклап калды.

*   *   *

Гадәттә ата-ана үз баласына исемне нәрсәнедер уйлап, күздә тотып куя. Нәгыймә һәм Терекул Айтматовлар, бәлкем, улларының киләчәктә бөек зат буласын аңлы-аңсыз рәвештә тоеп, аңа Чыңгыз исеме бирәләр. Мәгълүм ки, аның адашы — Чыңгыз хан (ул да яртылаш татар кавеменнән) — гаскәр, кылыч белән ярты дөньяны яулап алган, җиһангир булган. Кыргыз-татар улы Чыңгыз Айтматов исә каләм, кодрәтле сүз белән бөтендөнья укучыларының күңелен яулап, җиһангир-әдип буларак танылды, кешелек тарихына игелекле гамәлләре, «игү ат» белән кереп калды. Айтматов дулкыны тынмыйча, киләчәктә дә адәм балаларының күңелен дулкынландырыр, гафләт-манкортлыктан саклар, инсанилыкны үстерергә ярдәм итәр. Моңа минем иманым камил.

Мәдәни җомга (Казан). – 6,13.12.2013